**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

2025елның 29 гыйнвары 130 номер

# КАРАР

## 2025 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар хокукларын яклау буенча комплекслы планны раслау турында

«2014-2025 елларга Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын яклауның комплекслы системасын үстерү» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру буенча төп чаралар планын үтәү йөзеннән, шулай ук Татарстан Республикасы Лаеш районында кулланучылар хокукларын яклауны камилләштерү максатларында карар бирәм:

1. 2025 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар хокукларын яклау буенча комплекслы планны (Кушымта) расларга.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) .

3. «2024 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы башкарма комитетының кулланучылар хокукларын яклау буенча комплекслы планны раслау турында» 2024елның 11 гыйнварындагы 39 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисадый мәсьәләләр буенча урынбасары Л. М. Җамалиевка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**

Лаеш муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның «29» гыйнварындагы
130 номерлы карарына кушымта

**2025 елга Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының кулланучылар хокукларын яклау буенча комплекслы планы**

| № т/б | Чараның исеме | Үтәү вакыты | Башкаручылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Кулланучыларга консультацияләр бирү, кулланучылар законнары буенча аларның хокукларын аңлату | Даими | Икътисад һәм эшкуарлык бүлеге |
| 2 | Тиешле сыйфатта булмаган товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) ачыклаганда билгеләнгән тәртиптә федераль башкарма хакимият органнарына хәбәр итү | Даими | Икътисад һәм эшкуарлык бүлеге |
| 3 | Белгечләр тарафыннан чаралар оештыру:<br>- 15 мартта Бөтендөнья кулланучылар хокукларын яклау көнен үткәрү;<br>- Бөтендөнья сыйфат көнен үткәрү (ноябрьнең икенче пәнҗешәмбесе)<br>(мәгълүмати материалларны ММЧда, ТР Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру) | Февраль-март<br>Ноябрь | Икътисад һәм эшкуарлык бүлеге |
| 4 | Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итү:<br>- кулланучылар хокукларын яклау буенча комплекслы план;<br>- муниципаль берәмлекнең | Ел саен | Икътисад һәм эшкуарлык бүлеге |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | структур бүлекчәләре тарафыннан халыкны кабул итү графигы (сораулар буенча*);<br>- районның күпфункцияле үзәкләрендә кулланучыларны кабул итү сәгатьләре** | | |
| 5 | ММЧда, шул исәптән интернет-ресурсларда кулланучылар хокукларын яклау мәсьәләләре буенча материаллар әзерләү һәм бастырып чыгару | Айлап | Икътисад һәм эшкуарлык бүлеге |
| 6 | Кулланучылар өчен мәгълүмати материалларны Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты бинасында урнаштыру | Кирәк булган саен | Икътисад һәм эшкуарлык бүлеге |